ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Казан шәһәрендәге районнар чикләрен үзгәртү турында һәм «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 18 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Казан шәһәрендәге районнар чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.


**2 статья**

«Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» 2015 елның 25 апрелендәге 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 4; 2016, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Казан шәһәрендәге
районнар чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

Казан шәһәрендәге районнар чикләре
карта-схемасы



2) 2 нче кушымтада:

а) Казан шәһәренең Вахитов районы чигенең картографик тасвирламасының дүртенче абзацында «Нурсолтан Назарбаев урамының җөп ягы буйлап Габдулла Тукай урамына кадәр, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сара Садыйкова урамына кадәр,» сүзләрен «Нурсолтан Назарбаев урамының так ягы буйлап Вахитов мәйданына кадәр, Техника һәм Габдулла Тукай урамнарын кисеп үтеп, Вахитов мәйданының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк ягы буйлап көнбатышка таба бара, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап төньякка таба Сара Садыйкова урамына кадәр уза,» сүзләренә алмаштырырга;

б) Казан шәһәренең Идел буе районы чигенең картографик тасвирламасының беренче абзацында «Нурсолтан Назарбаев урамының җөп ягы буйлап Габдулла Тукай урамына кадәр, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап Сары Садыйкова урамына кадәр,» сүзләрен «Нурсолтан Назарбаев урамының так ягы буйлап Вахитов мәйданына кадәр, Техника һәм Габдулла Тукай урамнарын кисеп үтеп, Вахитов мәйданының көньяк-көнчыгыш ягы буйлап көньяк-көнбатышка таба һәм көньяк ягы буйлап көнбатышка таба бара, Габдулла Тукай урамының җөп ягы буйлап төньякка таба Сара Садыйкова урамына кадәр уза,» сүзләренә алмаштырырга;

в) Казан шәһәре Совет районы чигенең картографик тасвирламасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Совет районының басу аша кишәрлеге («Фәнни шәһәрчек») чиге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы белән чиктәш җирдә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең басу аша кишәрлеге («Фәнни шәһәрчек») чиге буйлап уза.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2023 ел, 19 декабрь
№ 129-ТРЗ

«Казан шәһәрендәге районнар чикләрен үзгәртү турында һәм «Казан шәһәрендәге районнар чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

Казан шәһәрендәге районнарның
үзгәрешләр исәпкә алынган чикләре
карта-схемасы

